ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.04.2020 г. Заинск № 298

**«Зәй муниципаль районының муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 29 июнендәге 1089 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

«Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 21 маендагы 413 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

## карар бирә:

1. «Зәй муниципаль районының муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 29 июнендәге 1089 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (2018 елның 17 декабрендәге 1864 номерлы, 2019 елның 22 мартындагы 151номерлы, 2019 елның 17 декабрендәге 646 номерлы, 2019 елның 20 декабрендәге 648 номерлы, 2020 елның 10 июнендәге 247 номерлы карарлар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

VII бүлектә:

1 пунктның бишенче абзацында «сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7. Тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) билгеле бер категорияләре белән эшләгән өчен компенсация характерындагы түләү аерым мәгариф оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә бирелә.";

7.1 пунктта:

беренче абзацта «сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

унберенче абзацта «сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.2 пунктының беренче абзацында «сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

15нче таблица исемендә «сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге нигезләмәгә 1нче кушымтада "Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар берлеге, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы ведосмство (тармак) бүләкләре өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр" бүлегенең 2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2.6 пунктча белән тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| "2.6. | «Мәгариф отличнигы» билгесе; |

күрсәтелгән карар белән расланган Зәй муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

III бүлекнең 2 пунктында «беренче - икенче төркем белән» сүзләрен «бер - ике төркем белән» сүзләренә алмаштырырга;

V бүлекнең 6 пунктына түбәндәге эчтәлекле уникенче абзацны өстәргә:

2020 елның 1 гыйнварына кадәр ике айдан өч яшькә кадәрге балалар өчен ике яшь төркемендә, өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балалар өчен өч яшь төркемендә хезмәт күрсәткән педагогик хезмәткәрләрнең һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәрендә эшләүчеләргә хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 17 декабрендәге 644 номерлы "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген, хезмәтнең катлаулылыгын саклауны исәпкә алып, норматив финанслау турында" карары үз көченә кергәнче түләнә торган күләмдә башкарыла.";

әлеге нигезләмәгә 1нче кушымтада "Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар берлеге, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы ведосмство (тармак) бүләкләре өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр" бүлегенең 2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2.6 пунктча белән тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| "2.6. | «Мәгариф отличнигы» билгесе; |

күрсәтелгән карар белән расланган Зәй муниципаль районы өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә кушымтаның "Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар берлеге, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы ведосмство (тармак) бүләкләре өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр" бүлегенең 1 таблицасына түбәндәге эчтәлекле 2.7 пунктча өстәргә:

| | |
|---|---|
| "2.7. | «Мәгариф отличнигы» билгесе; |

2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В.Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **И.Ф.Хафизов**

Л.Р.Печина
3-27-42